СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның "30" маеннан № 21-67

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы карары белән расланган 2017 елның 22 июньдәге 36-57 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»

«Ветеринария турында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы карары белән расланган «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы карарлары редакциясендә: 10.09.2018 № 57-92, 24.06.2019 № 72-118, 29.04.2021-10-26 номерлы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III бүлекнең 186 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) терлекләр авыруларын кисәтүне һәм терлекчелек продуктларының ветеринария-санитария ягыннан иминлеген тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын гамәлгә ашырырга, терлекчелек биналарын һәм терлек азыгын саклау һәм терлекчелек продуктларын эшкәртү корылмаларын тиешле хәлдә тотарга, әйләнә-тирә мохитне терлекчелек калдыклары белән пычратмаска;».

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталының рәсми сайтында «Интернет» телекоммуникация челтәре сайтында - http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советының Законлылык, экология, җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Җ.Г. Гайфетдинов